ИСПОЛНИТЕЛЬНЫЙ КОМИТЕТ
ЛЕБЕДИНСКОГО
СЕЛЬСКОГО ПОСЕЛЕНИЯ
АЛЕКСЕЕВСКОГО
МУНИЦИПАЛЬНОГО РАЙОНА
РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ
АЛЕКСЕЕВСК
МУНИЦИПАЛЬ РАЙОНЫНЫҢ
ЛЕБЕДИНО АВЫЛ ҖИРЛЕГЕ
БАШКАРМА КОМИТЕТЫ

**ПОСТАНОВЛЕНИЕ** **КАРАР**

30.01.2024 с.Лебедино № 8

**2022 елның 21 мартындагы 8 номерлы «Татарстан Республикасы Алексеевск муниципаль районының Лебедино авыл җирлегендә белешмә (өземтә) бирү буенча муниципаль хезмәт күрсәтүнең Административ регламентын раслау турында» карарга үзгәрешләр кертү хакында**

«Дәүләт һәм муниципаль хезмәтләр күрсәтүне оештыру турында» 2010 елның 27 июлендәге 210-ФЗ номерлы Федераль законны гамәлгә ашыру максатларында, Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының «Татарстан Республикасы башкарма хакимиятенең республика органнары тарафыннан дәүләт хезмәтләре күрсәтүнең административ регламентларын эшләү һәм раслау тәртибен раслау һәм Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының аерым карарларының үз көчләрен югалтуын тану хакында»2022 елның 28 февралендәге 175 номерлы карарына таянып

карар бирәм:

1. Татарстан Республикасы Алексеевск муниципаль районы Лебедино авыл җирлеге Башкарма комитетының 21.03.2022 ел, №8 карары белән расланган Татарстан Республикасы Алексеевск муниципаль районы Лебедино авыл җирлегендә белешмә (өземтә) бирү буенча муниципаль хезмәт күрсәтүнең Административ регламентына түбәндәге үзгәрешләрне кертергә:

-3.3.2.1 пунктының 11 абзацын түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«Формалаштырылган гаризаны формат-логик тикшерү бердәм портал тарафыннан автомат рәвештә орган (оешма) билгеләгән таләпләр нигезендә, мөрәҗәгать итүче тарафыннан сорауның электрон формасындагы һәр кырын тутыру процессында башкарыла. Бердәм портал тарафыннан дөрес тутырылмаган электрон формадагы сорау кыры ачыкланганда, гариза бирүчегә ачыкланган хатаның характеры һәм аны бетерү тәртибе турында турыдан-туры сорауның электрон формасындагы мәгълүмати хәбәр аша хәбәр ителә.»;

2. Әлеге карарны Интернет мәгълүмат-телекоммуникация челтәрендәге Татарстан Республикасы Алексеевск муниципаль районының рәсми сайтында http://alekseevskiy.tatarstan.ru һәм Татарстан Республикасының Рәсми хокукый мәгълүмат порталында урнаштырырга.

3. Әлеге карарның үтәлешен контрольдә тотуны үз артымда калдырам.

**Татарстан Республикасы**
**Алексеевск муниципаль районы**
**Лебедино авыл җирлеге**
**Башкарма комитеты җитәкчесе** **Ю.И. Тюкарев**